МИНИСТЕРСТВО
ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И
СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ
РЕСПУБЛИКИ
ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ
БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ
СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

________29.10.2021_________ г.Казань № ____795________

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2021 елның 16 ноябрендә 8096 номеры белән теркәлде

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгында коррупция юнәлешендәге фактлар буенча гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү тәртибен раслау турында

«Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 21 статьясы нигезендә боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгында коррупция юнәлешендәге фактлар буенча гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү тәртибен (кушымтада бирелә) расларга.
2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының структур бүлекчәләре җитәкчеләренә хезмәткәрләрне әлеге боерык белән таныштырырга.
3. Бу боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча министрның беренче урынбасары Р.Ф.Вәлиулловны җаваплы итеп билгеләргә.

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт,
халыкны эш белән тәэмин итү һәм
социаль яклау министрлыгының
2021 елның 27 октябрендәге
795-пр номерлы боерыгы белән
расланды

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгында коррупция юнәлешендәге фактлар буенча гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү тәртибе

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгында коррупция юнәлешендәге фактлар буенча гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү тәртибе (алга таба – Тәртип) «Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 21 статьясын үтәү йөзеннән эшләнгән һәм коррупция фактлары буенча гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау үзенчәлекләрен билгели, коррупция фактлары һәм янап акча алу, гражданнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен кысрыклау, хезмәт тәртибенә карата таләпләрне бозу, шулай ук Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгында (алга таба – Министрлык) Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәре (алга таба – дәүләт хезмәткәре), шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфасы булып тормаган вазыйфаны биләп торучы һәм Министрлык эшчәнлеге буенча техник тәэмин итү һәм хезмәт күрсәтүне гамәлгә ашыра торган хезмәткәр (алга таба – хезмәткәр) тарафыннан хезмәт урыныннан явызларча файдаланып гамәл кылу билгеләре булган башка гамәлләр турындагы белешмәләрне үз эченә ала.

2. Коррупция юнәлешендәге фактлар буенча мөрәҗәгать аны Министрлыкта теркәгән көннән соң икенче көннән соңга калмыйча Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры (алга таба – Министр) яисә аны алмаштыра торган зат тарафыннан, карау өчен, Министрлыкның дәүләт хезмәте һәм кадрдар бүлегенең коррупция һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы затына (алга таба – коррупция һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы зат) юнәлдерелә.

Мөрәҗәгатьтә коррупция һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы затка карата коррупция күренешләре фактлары турында белешмәләр булса, мөрәҗәгать, карау өчен, Министрлыкның эшләр идарәчесенә җибәрелә.

3. Коррупция юнәлешендәге фактлар буенча кергән мөрәҗәгатьтә әзерләнә торган, эшләнә торган яки бөтенләй хокукка каршы эш турында, шулай ук аны эшләргә әзерләнә, эшли торган яки эшләгән зат турында белешмәләр булса, мондый мөрәҗәгать теркәлгән көннән җиде көн узгач компетенциясе нигезендә хокук саклау органнарына җибәрелә.

4. Коррупция һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы зат, коррупция юнәлешендәге фактлар буенча мөрәҗәгатьне Министрлыкта теркәгән көннән алып эш көннәрендә исәпләнә торган биш көнлек чорда,

аны карый, шул исәптән алардагы белешмәләрне алдан анализлый һәм бәяли, дәүләт хезмәткәре, учреждение җитәкчесе, шулай ук хезмәткәр тарафыннан коррупциячел хокук бозулар кылуга күрсәтә торган белешмәләрнең (мәгълүматның) булуын яисә булмавын күрсәтеп, министрга белешмә (бәяләмә) җибәрә.

Министрлыкның эшләр идарәчесе коррупция юнәлешендәге фактлар буенча мөрәҗәгатьне коррупциячел юнәлештәге фактлар буенча мөрәҗәгатьне коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы зат тарафыннан карау өчен әлеге Тәртиптә билгеләнгән шул ук тәртиптә һәм шул ук срокларда карый.

5. Коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы зат яисә Министрлыкның эшләр идарәчесе тарафыннан коррупция юнәлешендәге фактлар буенча мөрәҗәгатьтә дәүләт хезмәткәре гамәлләрендә (гамәл кылмавында) коррупциячел хокук бозулар булуына күрсәтә торган белешмәләр (мәгълүмат) булуы ачыкланган очракта, Министр коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы зат яисә Министрлыкның эшләр идарәчесе тарафыннан мондый мөрәҗәгатькә белешмә (бәяләмә) тапшырылган көннән соң ике көн эчендә әлеге мөрәҗәгатьне «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы федераль законның 59 статьясы нигезендә, тикшерү уздыру өчен, Министрлыкның дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлегенә җибәрә.

Дәүләт хезмәткәре тарафыннан коррупциячел хокук бозу факты билгеләнгән очракта, аңа карата коррупциячел хокук бозу өчен түләттерү «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы федераль законның $59^3$ статьясында каралган тәртиптә гамәлгә ашырыла.

6. Коррупция юнәлешендәге фактлар буенча мөрәҗәгатьтә учреждение җитәкчесе гамәлләрендә (гамәл кылмавында) коррупциячел хокук бозулар булуына күрсәтә торган белешмәләр (мәгълүмат) булган очракта, Министр карары буенча Министрлыкка буйсына торган учреждение эшчәнлегенең юнәлешләрен тикшереп һәм координацияләп тора торган тиешле бүлеге (бүлекләре) тарафыннан коррупция юнәлешендәге фактлар буенча мөрәҗәгатьне Министрлыкта теркәгән көннән башлап эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көнлек срокта мондый мөрәҗәгатьтә бәян ителгән шартларга учреждение җитәкчесенең коррупция юнәлешендәге фактлар буенча мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән гамәлләрендә (гамәл кылмавында) учреждение эшчәнлеге өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне җайга сала торган закон нормалары бозылу очраклары булу предметына тикшерү гамәлгә ашырыла һәм уздырылган тикшерү нәтиҗәләре турында Министрга белешмә (бәяләмә) бирелә.

Тикшерү нәтиҗәләре буенча учреждение җитәкчесенең коррупция юнәлешендәге фактлар буенча мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән бозуларның җибәрелүе билгеләнсә, Министр коррупция юнәлешендәге фактлар буенча мөрәҗәгатьне, уздырылган тикшерү нәтиҗәләре турындагы мәгълүмат белән, карау өчен Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына буйсына торган учреждениеләр җитәкчеләренең вазыйфаи бурычларны үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерә яки китерә ала торган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килүе турында белдерүләрен карау буенча Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы комиссиясенә (алга таба – Учреждениеләр җитәкчеләренең

белдерүләрен карау буенча комиссия) учреждение җитәкчесе гамәлләрендә (гамәл кылмавында) законнарга каршы килә торган коррупция күренешләренең булуын яки булмавын, шул ук вакытта учреждение җитәкчесенең гаебе булуын яки булмавын билгеләү өчен кертә.

Тикшерү нәтиҗәләре буенча учреждение җитәкчесенең законнарга каршы килә торган гамәлләрендә (гамәл кылмавында) коррупция күренешләре ачыкланса, аңа Учреждениеләр җитәкчеләренең белдерүләрен карау буенча комиссия тәкъдимен исәпкә алып, Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 192 һәм 193 статьялары нигезендә дисциплинар җәза кулланыла.

7. Коррупция юнәлешендәге фактлар буенча мөрәҗәгатьтә хезмәткәрнең гамәлләрендә (гамәл кылмавында) коррупциячел хокук бозулар булуына күрсәтә торган белешмәләр (мәгълүмат) булган очракта, Министр карары буенча Министрлыкның дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлеге тарафыннан мондый мөрәҗәгатьтә бәян ителгән шартларга хезмәткәрнең коррупция юнәлешендәге фактлар буенча мөрәҗәгатендә күрсәтелгән гамәлләрендә (гамәл кылмавында) коррупциячел хокук бозуларның булуы предметына карата тикшерү гамәлгә ашырыла һәм уздырылган тикшерү нәтиҗәләре турында Министрга белешмә (бәяләмә) тапшырыла.

Тикшерү нәтиҗәләре буенча хезмәткәр тарафыннан коррупция юнәлешендәге фактлар буенча мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән хокук бозуларга юл куелган очракта, Министр үткәрелгән тикшерү нәтиҗәләре турында мәгълүмат белән коррупция юнәлешендәге фактлар буенча мөрәҗәгатьне эшче төркем каравына кертә, аның составы хезмәткәрнең законнарга каршы килә торган гамәлләрендә (гамәл кылмавында) коррупция күренешләре, шул ук вакытта хезмәткәрнең гаепле булу-булмавын билгеләү өчен, мөрәҗәгать кергән көннән алып 10 эш көненнән дә соңга калмыйча раслана.

Эшче төркем, үзе оештырылган көннән башлап эш көннәрендә исәпләнелә торган биш көннән дә артмаган срокта коррупция юнәлешендәге фактлар буенча мөрәҗәгатьләрне карый, хезмәткәрнең законнарга каршы килә торган гамәлләрендә (гамәл кылмавында) коррупция күренешләре, шулай ук мондый гамәлләрдә (гамәл кылмауда) хезмәткәрнең гаебе булу яисә булмавы турында белешмә (бәяләмә) әзерли һәм Министрга юллый.

Тикшерү нәтиҗәләре буенча хезмәткәрнең законнарга каршы килә торган гамәлләрендә (гамәл кылмавында) коррупция күренешләре булуы ачыкланса, аңа карата, эшче төркем киңәшләрен исәпкә алып, Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 192 һәм 193 статьялары нигезендә дисциплинар җәза кулланыла.

8. Министрлыкның структур бүлекчәсе тарафыннан Министрлыкта теркәгән вакытта коррупция юнәлешендәге фактлар буенча мөрәҗәгатьләр категориясенә кертелмәгән язма мөрәҗәгатьне караган вакытта аның, башка төрле мәгълүмат белән берлектә, шулай ук дәүләт хезмәткәре, учреждение җитәкчесе, хезмәткәр гамәлләрендә (гамәл кылмавында) коррупциячел хокук бозулар булуына күрсәтә торган белешмәләрне (мәгълүматны) дә үз эченә алуы ачыкланса, Министрлыкның структур бүлекчәсе аны теркәгән көннән башлап өч эш көненнән ким булмаган срокта Министрга яки алмаштыра торган затка дәүләт хезмәткәре, учреждение җитәкчесе, хезмәткәр гамәлләрендә (гамәл кылмавында) коррупциячел хокук бозулар булуына күрсәтә торган белешмәләр (мәгълүмат) булуы турында доклад язуы белән җиткерә. Министр мондый мөрәҗәгатьне, югарыда

күрсәтелгән белешмәләр (мәгълүмат) өлешендә карау өчен, коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы затка юллый.

Әлеге Тәртипнең 8 пунктындагы беренче абзацында күрсәтелгән мөрәҗәгать коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы зат гамәлләрендә (гамәл кылмавында) коррупциячел хокук бозулар булуын күрсәтә торган белешмәләр (мәгълүмат) булса, мондый мөрәҗәгать, бу өлештә карау өчен, Министрлыкның эшләр идарәчесенә җибәрелә.

Әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән мөрәҗәгатьне карау дәүләт хезмәткәре, учреждение җитәкчесе, хезмәткәр гамәлләрендә (гамәл кылмавында) коррупциячел хокук бозулар булуга күрсәтә торган белешмәләр (мәгълүмат) булган өлешендә карап тикшерү коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы зат һәм Министрлыкның эшләр идарәчесе тарафыннан коррупция юнәлешендәге фактлар буенча мөрәҗәгатьне карау өчен әлеге Тәртиптә билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда гамәлгә ашырыла.

9. Коррупция юнәлешендәге фактлар буенча мөрәҗәгать юллаган гражданинга коррупция юнәлешендәге фактлар буенча мөрәҗәгатьне теркәгәннән соң 30 көннән дә соңга калмыйча язмача җавап җибәрелә, ә «Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы федераль законның 12 статьясындагы 2 өлеше нигезендә мөрәҗәгатьне карау срогы озайтылган очракта, җавап гражданинга белдерүдә күрсәтелгән срокны озайту вакыты тәмамланганчы, ләкин коррупция юнәлешендәге фактлар буенча мөрәҗәгатьне теркәгән көннән 60 көннән дә соңга калмыйча җибәрелә.

10. Коррупция юнәлешендәге фактлар буенча мөрәҗәгать юллаган гражданинга җавап әзерләү коррупция һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы зат тарафыннан гамәлгә ашырыла, анда коррупция юнәлешендәге фактлар буенча мөрәҗәгатьне карау нәтиҗәләре турында мәгълүмат булырга тиеш.

Әлеге Тәртипнең 2 пунктындагы икенче абзацында һәм 8 пунктындагы икенче абзацында күрсәтелгән очракларда гражданинга җавап әзерләү Министрлыкның эшләр идарәчесе тарафыннан башкарыла.

11. Коррупция юнәлешендәге фактлар буенча мөрәҗәгатьләр белән эшләүче вазыйфаи затлар, Россия Федерациясе законнары нигезендә хезмәт мәгълүматларын һәм конфиденциаль характердагы белешмәләрне саклау өчен билгеләнгән тәртиптә шәхсән җаваплы була.